**Мингалим** Рөстәм

# Өч үрдәк

Балалар өчен шигырьләр һәм хикәяләр

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2012

УДК 821.512.145-1-32-93
ББК 84(2Рос=Тат)-5/4
М50

Төзүчесе *Ләбиб Лерон*

Рәссамы *Илдус Әҗемов*

**Мингалим, Р. Г.**

Өч үрдәк : балалар өчен шигырьләр һәм хикәяләр / Рөстәм Мингалим ; [төз. Л. Ле-рон ; рәссамы И. Әҗемов]. — Казан : Татар. кит. нәшр., 2012. — 71 б.: рәс. б-н.

ISBN 978-5-298-02280-4

УДК 821.512.145-1-32-93
ББК 84(2Рос=Тат)-5/4

ISBN 978-5-298-02280-4

© Татарстан китап нәшрияты, 2012
© Мингалим Р. Г., 2012

# ШИГЫРЬЛӘР

## Бүген миңа ни булган?

Бүген миңа ни булган,
дусларым?
Кулларыма карагыз да
белегез!
Бүген миңа ни булган,
дусларым?
Күлмәгемә карагыз да
белегез!
Бүген миңа ни булган,
дусларым?
Күзләремә карагыз да
күрегез!
Күрмәсәгез, белмәсәгез,
менә шул:
туган көнем бәйрәменә
керегез!

## Курчакларым

Курчакларым кечкенә,
курчакларым туңмасын.
Шуның өчен аларга
шакмаклардан өй ясыйм.
Өйләренә өстәл дә
конфет куям өстәлгә.
Конфетлары аз калса,
әзер торам өстәргә.
Чәй китереп өлгерәм,
рәхәтләнә тегеләр...
Безгә рәхәт, димиләр,
рәхмәт әйтә белмиләр:
курчакларым сөйләшмиләр,

шуңа күрә үсмиләр.

## Минем урын

Уяндым да урынымны җыймадым,
чыгып киттем, озак кына уйнадым.
Кайтып керсәм, үпкәләгән урыным,
идәнгә үк салган мендәр-борынын.
Үпкәләмәс, салмас иде борынын,
үзен үзе җыя алмый урыным,
үпкәсен дә әйтә алмый, сөйләшми,
мин югында и күңелсез дә яши.
Тузып ята чия кызыл юрганым,
ул да миңа бик үпкәли торгандыр.
Бөгәрләнгән ап-ак җәймә, кем белә,
елагандыр, бәлки, миңа үпкәләп.
Үпкәләмә, урынкаем.
...Менә бит —
җыештыргач, ул елмая белә бит!

## Галстуклы кәҗә

Безнең кәҗә —
купшы кәҗә,
туп-туп басып китә ул.
Матур китә,
матур кайта,
әнә кайтып җиткән ул.

Туп-туп басып
кайтып җиткән,
карап торам таң калып:
кара костюм,
ак якалы.
Галстугы — сакалы!

## Укый белә эти дә

«А» хәрефен тиз таныйм,
тагын күп хәреф таныйм.
Ничә хәреф таныйммы?
Анысын әти саный...

Укый белә әти дә,
укый белә әни дә.

Укы да укы гына —
китап күп безнең өйдә.

...Хәзер инде укырга
мин дә өйрәнеп киләм.
Инде бөтен китапның
рәсемен укый беләм.

## Энем бар

Шатлыгым бар,
өем бар,
әнием-әтием бар.
Минем гармуным да бар,
гармун хәтле энем бар.
Энем мине ярата,
мине күрсә, гел көлә.
Еласамы?!
Еласа, ул
сызып кына җибәрә
гармун тавышы белән.

## Хәтерлә әле

Песи авызында
күрдең син аны.
Хәтерлә әле,
ул ни булыр?
Һәм эт авызында
күрдең син аны.

Хәтерлә әле,
ул ни булыр?
Син хәтерләсәң-
хәтерләмәсәң дә,
ул гел булыр.
Аның исеме,
исеме аның
тел булыр.

# Җиде чебеш

Җиде чебеш: «Пи-пи!» — ди,
бодай сиптем аларга.
Җиде чебеш: «Пи-пи!» — ди,
тары сиптем аларга.

Алар һаман: «Пи-пи!» — ди,
димәк, алар: «Ипи!» — ди.

Алып килдем ипи дә...
Ашыйк бергә, пипиләр!

# Кая киткән?

Минем әти кайтмый бит,
кая киткән, ник киткән?
Бик сагындым аны мин,
ул сагынмый да микән?
Инде хәйлә таптым мин
әтиемне күрергә:
күзем ачсам — әти юк,
күзем йомсам — күренә.

# Тамчы тотам

| | |
|---|---|
| Тамчы тотам,<br>тамчы тотам. | Минем учны<br>тишә алмый, |

| | |
|---|---|
| Тамчы, тамчы,<br>тизрәк там!<br>Әни миңа<br>әйткән иде:<br>— Тамчы ташны<br>тишә, — диеп. | кара, ничек<br>тора биеп.<br>Тамчы тотам,<br>тамчы тотам.<br>Тамчы, тамчы,<br>тизрәк там! |

# Кызык рәсем

Булган икән бер малай,
ул еш кына елаган...
Алай ук еш еларга
сәбәбе дә булмаган,
ул барыбер елаган.

Аптырагач апасы —
ул малайның апасы,
ул елакның апасы —
кызык рәсем ясаган.

Шул рәсемне малайга
күрсәтә генә икән!
Малай, туктап елаудан,
кул чабып көлә икән!
Бот чабып көлә икән!
Баш кашып көлә икән!
Эч катып көлә икән!
ШУНДЫЙ рәсем
кирәк миңа,
кем ясый белә икән?

# Кемдер

Кил, яңгыр, кил, кил,
кемдер битен юмаган!
Ашаганда, боткасын
борынына буяган!

Кил, яңгыр, кил, кил,
безне өйгә куарсың!

Бит юмаган кемдерне
тотып, битен юарсың!
Кил, яңгыр, кил, кил,
шаулап-гөрләп яварсың!

# Ак куян

Абыем каядыр җыена,
мине алмаска тели:
— Җылы өйдә тыныч кына
рәсем ясап утыр! — ди.
— Иярт, абый?!
Ни күрсәм дә,
кайткач ясыйм, — дип әйттем.
Чаңгы такканымны көтте,
абый мине ияртте...
Тик ерак бара алмадык,
бер генә куян күрдек.
Борыным өши башлагач,
әйләнеп өйгә кердек.
Абыем: «Куян яса!» — ди,
өстәлгә кәгазь куя.
Ничек ясыйм ди инде мин
ак кәгазьгә ак куян.

# Әбиләргә барганда

Юл өстенә су җибәрә
язгы кояш, авыз ерып.
Су янында соры чыпчык
җырлап йөри чырык-чырык.

Булат кына мышык-мышык
елап тора юл буенда:
«Үтеп булмас, су тирәндер,
йә билдәндер, йә муеннан!

Нишләргә соң?
Әбиләргә
бара алмый
калам инде». —
Шул минутта
соры чыпчык,
пырлап, күккә күтәрелде.

Юл өстендә яткан суның
уртасына кунды чыпчык:
— Кара, Булат, тирән түгел.
Курыкма, — ди, — әйдә чык, чык.

## Син, мин һәм карга

Сине әнкәң тудырган,
мине әнкәм тудырган.
Карганы кем тудырган?
Карганы көн тудырган.
Кем ярата карганы?
Көн ярата карганы.
Көн яшәтә карганы,
көн ашата карганы.
Карга ашап туя да
талга менеп утыра:
кар югында кар сорап,
көннең башын катыра.

## Үскәнемне күрмиләр

Озын-озын ике абый
безгә күрше торалар:
зур-зур күзлек
кигәннәр.
Минем янга килгәннәр.
Икәү көләләр миннән.
Синең авызың зур, диләр.
Авызың тулы сүз, диләр.

Үзең бәләкәй, диләр.
Үскәнемне дә күрмиләр,
үзләре — күзлеклеләр,
хa-хa!

## Сандугач турында

— Менә, — диләр, —
менә, — диләр, —
бөтен җирне,
бөтен көйне,
барлык телне белә, — диләр.
Шушы сандугач турында
ниләр генә сөйләмиләр?!

Талга кунып сайраганда,
кичә үзен очраттым.
Телен дә бик ошаттым:
— Минем учка кунып сайра,
тәти кошчык,
әйдә кил! — дим.

Ә сандугач дигәннәре
аңламады минем телне.

## Җил исте дә

| | |
|---|---|
| Җил исте дә,<br>тал сыгылды,<br>яфрагы<br>суга кагылды.<br>Суга баткан<br>кырмыскага<br>котылырга<br>җай табылды:<br>ул яфракка<br>үрмәләде. | Тал очына<br>йөгереп менде.<br>Яшел талга<br>рәхмәт әйтте,<br>җылы җилгә<br>рәхмәт әйтте.<br>Тавышын<br>без ишетмәдек.<br>Җил ишетте,<br>тал ишетте. |

# Ачып куйдым капкасын

Алдым төсле каләмнәр,
зур итеп өй ясадым.
Аннан
бакча ясадым.
Бакчасында
солы үсә,
бодай һәм тары да үсә,
ни кирәк — бары да үсә!
Алма, чия, карлыган!
Бай ясадым бакчасын.
Койма белән урадым да
ачып куйдым капкасын.
Килеп керде кәҗәләр,
килеп керде тавыклар,
үрдәкләр һәм
сарыклар...
Минем бакчага
чират.
Әнә килә
дүрт-биш ат, сыерлар
тезелгәннәр.
Капка ачык икәнне
кай ара сизенгәннәр?
Ярый инде, керсеннәр —
миннән рәхәт күрсеннәр.

# Күренеп тора

Бакчабызга очып төште
соры чыпчык.
Тәпиләре нечкә-нечкә,
борыны сары.
Күренеп тора —
юмарт чыпчык,
бала чыпчык.

Ул бирергә тели миңа
канатларын.
Мин алмадым,
алдамадым:
«Бар, бар, оч!» — дим.
Аңа канат бик кирәген
беләм ич мин.
Канатсыз ул
оясына оча алмас.
Җирдә калыр,
песидән дә кача алмас.

# Колак сәгате

Стена сәгате була,
кесә сәгате була,
ә нигә булмасын, дим.
Кул сәгате дә була,
аяк сәгате дә булыр,
ә нигә булмасын, дим.
Колак сәгате дә булыр,
ә нигә булмасын, дим.
Кызыл бозау колагына
сәгать тагып куйдым мин.
Тау битендә йөрербез,
вакытны да белербез.
Әниемнең кул сәгатен
кайтарып та бирербез.
...Бозау, сәгать, мин —
өчәү —
әле бергә йөрибез.
Сәгать кебек
йөрибез.

# Песи күзе турында

Безнең өйдә бер песи бар,
койрыгында бер күзе бар.

Аягында, колагында,
аркасында да күзе бар.
Шуңа да яхшы күрәдер,
сеңлемә һич тоттырмый ул.
Үзем тотып бирер идем,
ул миңа да тоттырмый шул.
Ялт итә дә юкка чыга,
әфсен белгән песи сыман.
Ул миңа да, сеңлемә дә
үпкәләгән кеше сыман.
Килешергә җай эзлибез,
шундый әйбәт песи үзе.
Чынлап әйтсәм, чын песи ул,
икәү генә аның күзе.

# Яу, яу!

Кызу чагы көннәрнең,
яңгыр көтә гөлләрем:
— Кил, яңгыр, яу, яу!
— Яу, яңгыр, яу, яу!
Яңгыр көтә бакчабыз,
яңгыр көтә барчабыз:
— Кил, яңгыр, яу, яу!
— Яу, яңгыр, яу, яу!
Яңгыр килде яңгырап,
каршы алдык без җырлап:
— Кил, яңгыр, яу, яу!
— Яу, яңгыр, яу, яу!

# Күк-кү!

Кечкенә куян
көн үзәгендә
йоклый урманда,
агач төбендә...

Бу бәби куян
һаман уянмый.
Кошлар уята
бәби куянны.
— Чү, чү-чү! Чүти-чүти!
— Юти-юти-юти!
— Итю-итю-итю!
— Тюр-р-р, тюр-р-р!
— Күк-кү! Күк-кү! Күк-кү!

Бу бәби куян
йоклый ул күптән.
Ул уянганны әнкәсе көтә...
Тыңлап кошларны,
аңлап сүзләрен,
кечкенә куян
ача күзләрен.
— Чү, чү-чү! Чүти-чүти!
— Юти-юти-юти!
— Итю-итю-итю!
— Тюр-р-р, тюр-р-р!
— Күк-кү! Күк-кү! Күк-кү!

# Күбәләк

Мин дә күләбәк, дигән
ак күбәләкнең кызы.
Уйныйк икәүләп, дигән
ак күбәләкнең кызы.
Күбәләк тә күләбәк
уйнаганнар икәүләп,
һәм
Күләбәк югалган,
ярый аннан табылган.
Оча-оча,
уйный-уйный,
үсә-үсә,

ул күләбәк
зуп-зур күбәләк булган.

# Нишләр, әй, бу оя...

И сайрый сыерчык,
сайрый сыерчык.
Йә кунып сайрый ул,
йә уйный очып.

Шатлана сыерчык
оя тапканга.
Сыерчык килгәнгә,
оя шатлана...

Мөлдери сөенеч
яз һавасында.
Сөенеч,
сөенеч
колга башында.

Нишләр, әй, бу оя,
шатлыкка тулып?! —
Ул сайрап җибәрде
сыерчык булып!

# Кунак

Безнең якта кунак ул,
безнең кебек уйнак ул.
Уйнак булгач уйнарбыз,
уеныбыз менә шул!
Өчкә хәтле санарбыз,
йөгерешеп карарбыз.
Артта калган тай булыр!
Тайдан алда ат булыр!
Атны узып йөгерсә,
мактанчык кунак булыр.

Аңа рөхсәт, мактансын,
атны узып карасын.
Тайдан артта калмасын,
бер, ике, өч!

# Өч үрдәк

Кар өстендә өч үрдәк,
киемнәре кардан ак.
Әй, өч үрдәк, өч үрдәк,
исәнмесез, өч бак-бак!
Берсе әйтте: «Бак!» — диде.
Икенчесе: «Бак-бак!» — диде.
Өченчесе: «Бак-бак-бак!»
Әй, өч үрдәк, өч үрдәк,
өчегез дә бак та бак.
Сезгә багып торам бит,
мактанасыз бит кайчак.
Берсе әйтте: «Бак!» — диде.
Икенчесе: «Бак-бак!» — диде.
Өченчесе: «Бак-бак-бак!»
Ак киемле өч үрдәк,
аңладым телегезне.
Инде хәтта белдем мин
матур исемегезне.
Беренчегез Ак икән.
Икенчегез Ак-ак икән.
Өченчегез — Ак-ак-ак.

# Кыен хәл

| | |
|---|---|
| Ишегалды<br>бозлавык.<br>Бозлавыкта<br>бер тавык.<br>Тукта, тукта, | Әтәч килде<br>ярдәмгә,<br>калды кыен<br>бер хәлгә:<br>ярдәм итәр |

| | |
|---|---|
| ни булды?<br>Тавык таеп<br>егылды! | юлы юк.<br>Канаты бар,<br>кулы юк. |

# Хаталы шигырь

*(Мәсьәлә)*

Яуды, яуды, яугыр яуды —
атна буе коеп торды.
Бу яугырлы көннәр мине
бик туйдырды, боектырды.
Яумагырлы көннәр килсә,
мин балыкка йөрер идем.

...Бу шигырьдә
ничә хата?
Үзем әйтеп бирер идем —
белмим шул.
Ә
кем
белә?

# Иң зур кеше

Күпне белгән кеше
ул зур кеше була.
Күптән күпне белгән
бик зур кеше була.
Бик зур кешегә дә
тиң зур кеше була.

Әти-энидән дә
зуррак кеше
булмый.
Шуны белгән кеше

иң зур кеше була.

# Авылга яңгыр килә

Тиз генә тышка чыктым,
Әнкәй өйдә аш бүлә.
Күкне болыт каплаган,
Авылга яңгыр килә.
Әнкәй ашын бүлгәнче,
Яңгыр килеп яуганчы,
Бик аз гына вакыт бар,
Бераз уйнап алыймчы.
Тау өстенә йөгердем,
Болытларга сикердем.
Болытлар артындагы
Кояшны барып күрдем.
Кояш әйтте, син, малай,
Өеңә тиз кит, диде.
Әнкәң көтә бит, диде.
Кояшка күз кыстым да
Кабат болытка чумдым.
Кара болытка чумдым.
Болыт шундый ачулы.
Мин монда озак тормыйм,
Мин бит әнкәйне тыңлыйм.
Ялтырап яшен чыкты
Һәм мине куып китте.
Яшен куып җитмәде —
Мин өйгә кайтып җиттем.
Әнкәй ашын бүлгәнче,
Яңгыр килеп яуганчы,
Шулай уйнап алдым шул,
Шулай уйлап алдым шул.
Инде ашарга утырдым,
Тәрәзәгә карап куям,
Яңгыр
Чиләкләп коя.

## Дусларың гына булсын!

Егылсаң торып була,
Торсаң йөгереп була,
Йөгерсәң җитеп була —
Дусларың гына булсын!
Сөйләшеп, уйнап була,
Күп нәрсә белеп була,
Шаярып-көлеп була —
Дусларың гына булсын!
Күңелле яшәп була,
Үсеп һәм нығып була,
Дошманны егып була —
Дусларың гына булсын!

## Ә сәгать келт-келт итә

Йоклаган сәгать иде,
Сатып алдык кибеттән.
Хәзер тора өстәлдә,
Йокламый ул бик күптән.
Күрсәтә ул вакытны,
Соңгармаска икәнне,
Кунакларга күрсәтә
Китәр вакыт җиткәнне.
Кайтыр чагын әтинең
Сөйләп тора әнигә.
Әйтә ашның пешкәнен,
Кайнаганын чәйнең дә.
Көн уза да, кич була,
Өй эче йоклап китә.
Ә сәгать келт-келт итә,
Ә сәгать келт-келт итә.
Җәй үтә дә, көз була,
Көз уза да, кыш җитә.
Ә сәгать келт-келт итә,
Ә сәгать келт-келт итә.
Кибеттәге шикелле

Йоклар иде бер тагын,
Йоклама, дип, әтием
Көн дә бора колагын.

## Тояклар җирне кага

Әй сукты бәйрәм сәгате
Бәрхет тау башларында.
Мәйданга малайлар кереп
Көрәшә башладылар...
Көрәшәләр болыннарда,
Урманда-аланнарда.
Тәгәрәп алмаш өлгерә
Көрәшче агайларга!
Татарстан карап тора
Сабан туе кызганны.
Малайлар күккә менәләр,
Балакларын сызганып.
Малайлар атта киләләр,
Тояклар җирне кага.
Көчле малайлар үскәнне
Хәбәр итеп дөньяга,
Тояклар җирне кага.

## Дусларым

Өебез урман буенда —
Якты Идел ярында.
Каргалар да, чыпчыклар да
Минем белән дус монда.
Һәм җиләкләр, һәм чәчәкләр,
Дус каеннар, имәннәр
Безнең капка янына ук
Мине эзләп килгәннәр.
Килеп чыга төлке дус та
Минем хәлне белергә.
Мин чирәмдә кырын ятам
Ак казлар белән бергә.

# Хәй күршесе Хөсәен

Хәй күршесе Хөсәен
Хәйдән көлә көн саен:
«Әтиеңнән башка син
Ашый да белмисең! — ди. —
Әтиеңнән башка син
Сөйли дә белмисең! — ди. —
Әтиеңнән башка син
Йөри дә белмисең! — ди. —
Шуңа гел әтиеңә
Тагылып йөрисең!» — ди.
Күп сөйләшеп тормый Хәй,
Машинага утыра.
Әтисе
Машина йөртә,
Хәй карап кына тора.
Өйрәнеп кенә тора
Һәм аңлап кына тора.
Әле бермәл Хөсәен
Хәй янына утырыр.
Машинаны Хәй йөртер,
Хөсәен карап торыр,
Елмаеп бераз гына.
Хәй кабатлар көн саен:
«Машина йөртергә сине
Өйрәтимме, Хөсәен?»

# Крокодил күрдек

Кичә киногa кердек,
Кинода
Зур су күрдек.
Әйе,
Бик зур су күрдек,
Суда
Крокодил күрдек.

Крокодил да
Бик зур иде,
Күзләре дә зур иде,
Авызы да зур иде.
Ул туры безгә килде.
Сикереп куйдым
Урында.
Әти тотты кулымнан:
«Чын түгел ич, кино бу,
Улым, курыкма!» — диде.
Хәтта: «Безнең елгада
Крокодил юк ла», — диде.
Анысын мин дә беләм,
Кечкенә безнең елга —
Безнең янга крокодил
Килеп чыкмасын өчен
Шулай кечкенә булган.

# Кыюлык

Җыелдылар малайлар,
Чаңгы табып бирделәр:
— Без кыюны яратабыз,
Әйдә, шуыйк бер, — диләр, —

Шунысын да онытма,
Биек, — диләр, — тавыбыз.
Шуа белми шуганнарның
Җимергәли авызын!

— Егылу ул — кызык эш,
Егылу ул шәп! — димен.
Чаңгы шуа белмәвемне
Тегеләргә әйтмимен.

Менсәк тауның башына,
Калды башны кашырга.
Ничек кенә төшәргә соң,
Кем артына басарга?

Егылуың шәп эш тә,
Егылмавың да әйбәт:
Чаңгыларны кулга тотып
Төшеп киттем җәяүләп.

# Торналар

Торыйк-торыйк
торналар
Китеп барганны күрдем.
Мин дә, торрыйк-торрыйк, дип,
Артларыннан йөгердем.

Торналар белән бергә
Мин очарга уйладым.
Талпынып та карадым —
Кулым канат булмады.
Булмады шул, булмады, дип,
Мин кайгырып та алдым.
Очып китми калганыма
Әнкәй шундый куанды.

# Самолёт

Кызу барган уңайга
очып китте трамвай,
оча-оча трамвай...
Әй,
трамвай дип инде
ялгыш кына әйтелде!

Оча-оча самолёт,
оча безнең самолёт!
Оча-оча биектә —
кинәт туктадык күктә.
Күктә түгел икәнбез,
җиргә төшеп җиткәнбез.

# Кыш рәсеме

Сузды да кыш уң кулын
Алды минем тавымны.
Алды минем сукмакны,
Сыгылмалы талымны.
Гөрелдәвек чишмәне
Үрелеп алды, тиз алды.
Җәеп тора сул учын,
Елгамны шуңа салды.
Ул ак учы өстенә
Салды озын юлларны.
Тылсыммы бу, чынмы бу?
Бар да шуңа сыярмы?
Малайларны, кызларны
Ул учына тутырды.
...Ялгыз калыр хәлем юк,
Мин дә менеп утырдым.
Нәрсә булса, шул булыр —
Бергә-бергә күрербез.
Язны күрсәк,
Учыннан
        чирәмгә сикерербез.

# Ничә кабат чиртте?

*(Мәсьәлә)*

Бер кат әйтте әти —
ишетмәдем.
Икенче кат әйтте —
ишетмәдем.
Өченче кат әйтте —
ишетмәдем.

Аннан ул башыма
шундый әйбәт чиртте.

Искә төште, әти,
ишеткәнмен!
Ишеткәнмен!
Ишеткәнмен!

# Кошлар һәм ташлар

Бер җирдә
Күп таш булган.
Ташлыкта
Күп кош булган.
Ялгыш
шунда барып чыктым
Һәм кошларны куркыттым.
Ташларны да куркыттым!
Кошлар очып киттеләр,
Ташлар очып киттеләр! —
Шундый хәл булып алды.
Башыма таш төшмәсен дип,
Үзем дә куркып калдым.

# Бездә шулай

Безнең авыл кечкенә,
исеме аның — Дәүйолдыз.
Ярты авыл бездә — кыз,
ярты авыл — малай,
бездә шулай.
Мин дә — кечкенә малай,
өстемдә яңа күлмәк.
Ул — апам биргән бүләк,
түш кесәсе дә бар,
әйе, шулай.
Кесәсендә күлмәкнең
нәрсә бар, беләсезме?
Әллә үзем әйтимме? —
Нәни генә бер эт,
менә шулай!

Ул ник анда димәгез,
минем янымда йөрер.
Дошманым килсә өрер,
дусларыма өрмәс,
шулай, шулай.
Өргәне дә юк аның,
бүредән дә усал эт!
Өрер сәбәп тапмый бит,
бөтен авыл — дустым,
бездә шулай.
Этне үзем ясадым.
Әйе, кәгазьдән генә:
кесәмдәге кәгазь эт
шуны үзе дә белә!
Менә!

# Авызсыз багана

Басып тора багана,
Бер авызсыз багана.
Өлкәннәргә эндәшә,
Эндәшә һәр балага,
Менә сезгә багана!
Күзе белән эндәшә,
Авызы булмаганга.
Багананың өч күзе,
Өч күзендә — өч сүзе.
Берсе аның яшел сүз,
Икенчесе сары сүз,
Өченчесе кызыл сүз.

# Кара ат

Кара ат авылда,
Ак җире бар ялында.
Ияре бар, йөгәне бар,
Йөгәнендә җизләре бар.
Мин гел шул ат янында.

Әти кебек сызгырып,
Су эчерәм атыма.
Чабып китсәм, каршымдагы
Малай-шалай, каз-үрдәкләр
Куркып читкә атыла.
Әй кешеләр сөйлиләр,
Иң яхшы ат ул, диләр.
Ияр түгел синең урын,
Син чамала, юеш борын,
Очып калырсың, диләр.

Очып калган юк минем,
Төшеп калган юк минем.
Борыным да юеш түгел,
Иярдә дә нык утырам,
Йөрәгем дә нык минем.

# Дөньяда бер эт бар иде

Дөньяда
Бер эт бар иде —
Кечкенә,
Йомшак кына,
Ак кына,
Тик маңгаенда
Кара тап бар чак кына.
Хуҗасы — шаян малай —
Этне ярата иде,
Аны ашата иде.
Ә бермәлне нигәдер
Яратмый да башлады,
Ашатмый да башлады.
Илтеп шәһәр эченә
Адаштырды ул аны.
Шушы көнне үк төнлә
Эте керде төшенә:
— Ашыйсым килде,
Кайттым! —ди.

Кечкенә,
Йомшак кына,
Ак кына,
Тик маңгаенда
Кара тап бар чак кына.
Икенче көнне дә төнлә
Эте керде төшенә:
Бер ишектән аны тибеп
Чыгардылар кешеләр.
Иртүк торды да малай
Китте эзләргә этен.
Югалту ансат икән дә,
Аһ, читен табу, читен.
Эзли малай,
Тапмый этен
Бик күптән инде менә.
Бик күптән инде һәр төндә
Эте төшенә керә:
Йөгереп керә
Йә тик тора —
Кечкенә,
Йомшак кына,
Ак кына,
Тик маңгаенда
Кара тап бар чак кына.
Эзләмәсен малай этен,
Инде җирдә юк эт ул.
Кая киткән соң, дисезме?
Төшкә әйләнде бит ул.

# Ике мин

Бер генәм, ди әнкәм дә,
Бер генәм, ди әткәм дә.
Безнең өйдә ике мин,
Ике миннең берсе — мин.
Икенчесе кайда соң?
Әйе, белмисез генә.
Икенчесе, икенчесе

Яши безнең көзгедә.

# ХИКӘЯЛӘР

## Бүген төнлә күккә кара

— Мин Казансу аша йөзеп чыга алам! — диде Фәргать Алсуга.

Ул зур малай шул. Йөзә дә беләдер.

Аннан соң аларның машиналары да бар. Зәңгәр машина, джип, диләр. Әтисе алган.

Фәргатьнең әтисе — милиционер.

Ул төнлә тәртип бозып, сугышып йә урлашып йөргән кешеләрне тота икән. Шулай кирәкле, авыр эштә эшләгәч, акча да күп ала икән. Моны Фәргать сөйләгән иде. «Алар ел саен ерак диңгезгә ял итәргә бара. Анда Фәргатьне әтисе йөзәргә өйрәткән. Безнең диңгезгә барган юк шул әле»,—дип уйлады Алсу. Үзе Фәргатькә карап торды. Ул Фәргатьнең һәр хәрәкәтен игътибар белән күзәтә. Аның һәр сүзенә ышана. Фәргать кебек күп белүче малай башка җирдә юктыр да кебек.

— Фәргать!

— Нәрсә?

— Син биш тиенлек акчаны ашый беләсеңме?

— Беләм.

— Бакыр биш тиенлекнеме? Син аны ашыйсың да, бераздан ул минем колактан килеп чыгамы?—диде Алсу Фәргатькә.

— Нишләп синең колактан чыксын?! Ул минем эчтә була! — диде Фәргать.

— Ялгыш йотып җибәрәсеңме?

— Ялгыш түгел, чынлап.

— Син аны чынлап йотма, Фәргать. Ялгыш та йотма, чир-ләрсең,—диде Алсу.

— Фокус күрсәткәндә, акчаны йотарга ярамый. Миңа әткәй шулай әйтте... Ә мин Рәмзия апаның рәсемен ясый беләм, үзенә дә күрсәттем. «Бу бөтенләй миңа охшаган, — диде Рәмзия апа.— Чәче дә гел минеке төсле булган икән», — ди. Сиңа да күрсәтимме? Хәзер алып чыгам!

Зәңгәр, кара, кызыл һәм сары карандашлар белән ясалган «Рәмзия апа»ны Фәргать белән Алсу кабат-кабат карадылар. Бер бит кәгазьне тутырып торган бу рәсем Рәмзия апага бигрәк тә

юанлыгы белән охшаган иде.

Бераздан Фәргать болай диде:

— Мин үзебезнең машинаны йөртергә өйрәндем. Мин аны алга таба да, артка таба да йөртә алам. Выж-ж-ж! — диде Фәргать, авызы белән машина тавышы чыгарып. Кулы белән машина рулен борган кебек итте. — Рульне уңга борам, машина сулга чаба... Юк ла, уңга чаба! — дип төзәтте Фәргать хатасын. — Рульне сулга борам, машина сулга чаба... Чаба-чаба да әнә теге тауларга менеп китә, — диде ул, ерактагы тауларга күрсәтеп.

Таулар өстендә офык иде. Офыктан күк башлана. Анда юллар да күккә китәдер кебек. Алсуга шулай тоелды.

— Ә син хәзер бөтен күккә асфальт җәелгән икәнне беләсеңме?— диде Алсу, зур соры күзләре белән Фәргатькә туры карап.

Фәргать башта аптырап куйды, ләкин кинәт уе ачыкланып, хәтта бераз Алсуга ачуланып, болай диде:

— Син нәрсә?! Күк ул күк була. Анда нинди асфальт булсын ди?!

— Була шул. Менә күрерсең! — диде Алсу. — Бүген төнлә күккә кара, күк асфальтланган булыр... Күрерсең... Анда бик күп, бик күп машина булыр. Мин аларның үзем теләгәненә утырып китәрмен.

Шунда Фәргать Алсуның сүзен бүлде:

— Әллә син җүләрме? Әллә әкият капчыгымы син?

— Менә күрерсең! — диде Алсу.

Билгеле, Фәргать Алсуның сүзләренә ышанмады. Шулай да ул кичен, телевизор караганнан соң, Алсуны исенә төшерде. Әтисенә эндәште:

— Әти, син биш тиенлек акчаны ашый беләсеңме?

— Улым, ул бик каты булыр шул, тешне сындырыр. Кәгазь акча булса инде әллә... Анысы йомшаграк, тәм-ләрәктер дә.

— Мин бит аны чынлап ашарга димим, — диде Фәргать әтисенә.— Фокус күрсәтә беләсеңме, дим?

— Мин дә шуны әйтәм шул, — диде әтисе. — Менә син, эшләп акча алгач, миңа кайтарып бирерсең, фокус ясап карарбыз.

Фәргать һаман да ни өчендер Алсуны уйлады. Ул балконга чыгып күккә карарга булды... Төнге күктә йолдызлар. Алар тезелешеп, таралышып, җыелышып яна. Әйе, төнге күк тулы машина икән! Утларын кабызганнар да туктаганнар, барысы да Алсуны көтә.

Алсу өендә. Ул көндез күп уйнаган, арыган һәм инде ятып

йоклаган иде шул.

# Тау таптым

Кичә мин тау таптым. Бүген дә шул тауга шуарга барам. Берүзем генә барам. Инде мин зур бит.

Әнкәй елмаеп тәрәзәдән карап калды. Ул минем зур икәнне белә.

Күрше Гайнулла бабай да, олы борынын тәрәзәгә үк төртеп, мине карап калды.

Мин еракка китеп шуам, юлның теге ягына. Ә-әнә теге җиргә хәтле барам. Кичә дә шунда барган идем. Шунда мин үземә яхшы тау таптым. Чаңгым да яхшы.

Кар тирән. Карда бик күп эзләр бар. Төлке, бүре эзләре, диләр. Монда поши эзләре дә була, дип сөйлиләр. Мин үзем куян эзләрен генә таныйм әле, әтием күрсәтте.

Бүген көн салкын. Җил дә юк. Бөтен җир ап-ак! Өченче көн инде шулай. Мондый көннәрне мин санап барам.

Җайлап кына кар да ява башлады. Кар яуса, көн җылыта, дигән иде әти. Җылытыр, ахры.

Монда җәй көне нинди җылы иде! Чәчәкләр бар иде. Ак, зәңгәр, сары, ал чәчәкләр... Күбәләкләр!

Мин ак күбәләкләрне яратам. Кар бөртеге, ак булса да, күбәләк була алмый. Кыш көне күбәләк кар була, боз була...

Ә минем кулым да өшеми. Яңа бияләйләр кигәнгәдер инде. Әллә җылыта да микән?

Кара-кара! Кар бөртекләре ничек күп булып ява башлады!.. Әнә нинди эзләр күмелә! Бүре эзләредер әле, күмелсеннәр тизрәк. Алар мине бераз куркыта. Куян эз-ләреннән мин курыкмыйм. Тик куян эзләре күмелеп тә бетте шул инде... Кар һаман ява. Моннан безнең өебез күренеп тора. Әткәй эштә инде. Әнкәй әле дә тәрәзәдән карый микән? Гайнулла бабай да карыйдыр. Алар мине күрә микән? Хәзер мин үзем тапкан тауга менәм. Яңа карга яңа эз салам.

# «Сагындыңмы, улым, авылны?»

Бер малайны шәһәрдә калырга, бераз кунак булырга кыстадылар.

— Каласыңмы? Калсаң, мин сине килеп алырмын, — диде әтисе.

Малай беразга шәһәрдә калырга булды. Чөнки ул монда бергә уйнарлык дуслар да очратты. Әтисе сүзендә тора торган кеше. Ул малайны килеп алачак, әлбәттә.

Шулаен шулай да... Инде малайга шәһәрдә озаграк торды шикелле тоела башлады. Тизрәк әтисенең килүен көтә.

Әтисенең килүен көтеп, гел боегып кына тормый ул торуын. Гел кунак булып, өстәл янында сыйланып кына да утырмый. Яңа дуслары белән уйный. Якындагы кибеткә ипигә йөри.

Өйдә әле ипи бетмәгән, ипи кирәкмәгән вакытлар да була. Андый көннәрдә дә малай ипи кибетенә бара: бер бара, ике бара. Кичә, өйгә әле ипи кирәкмәсә дә, кесәсендә акчасы булмаса да, ул кибеткә өч мәртәбә барды... Шулай бара да киштәләрдәге түгәрәк, шакмак, ак, кара ипиләрне карап йөри. «Ипи дә алмый. Нишләп йөри бу малай? Әллә ипи чәлдерергә йөриме?» — дип уйлыйдыр кибетче апа.

Чәлдерергә йөрми ул. Нишләп йөргәнен малай үзе яхшы белә. Аңа шулай йөрү рәхәт, чөнки шәһәрдәге ипи кибетеннән авыл исе килә.

Бүген малай кибеттән ике ипи сатып алды. Кайтып керсә, ни күрсен — өйдә аны әтисе каршылады!

— Сагындыңмы, улым, авылны? Иртәгә кайтабыз! — ди.

Малай шатлыгыннан сүзсез торды. Аннан әтисен кочак-лап алды.

# Чуклы камчы

Бу күптән булган хәл.

Ул чакта да кояш елмайган. Агачлар яшелләнгән, үләннәр яшәргән. Кырда атлар кешнәгән. Юллардан атлар чабып үткән. Йортта да атлар булган. Яхшы атларны кыю кешеләр караган.

Яранның әтисе дә атлар караган икән. Тик Яран әле кечкенә булган. Ул ат өстендә әтисе алдына утырып кына йөри алган. Берүзе атта йөрергә бик кызыккан ул. Әтисе кебек сызгырып, атка су эчерәсе килгән. Әтисенең калын, бик күп чуклы камчысына да кызыккан.

— Әти, камчыңны миңа бир әле, — дигән.

— Юк, улым, бирә алмыйм. Син әле кечкенә. Менә тиздән үсәрсең. Минекеннән дә матур итеп үзеңә камчы үрерсең, — дигән

этисе.

— Мин бит камчы үрә белмим, — дигән Яран.

— Өйрәтермен, — дигән этисе.

Яранга исә хәзер үк камчы кирәк булган. Йортта, чәчәкле сукмакларда, Касады ярында, таллар янында аның камчы тотып йөрисе килгән.

Беркөнне Яран күршедәге дусты Гайрәтләргә кергән. Ишекләре бикле икән. Йортларында бер камчы күргән. Яран камчыны кулына алган да йорттагы кычытканнарны кыйнаган. Ялгыш үзенең аягына да суккан. Тик еламаган. «Яхшы камчы! — дип уйлаган Яран. — Әллә алып чыгыйммы икән?» Һәм Яран бу камчыны алып чыккан.

Ул өйләре артына ук килеп терәлгән каенлыкка кергән. Камчының чукларын тотып-тотып караган. Шуннан соң аны җиргә куйган. Үләннәр өстендә бөгәрләнеп яткан камчыга тагын бераз карап торган. «Бу эшне эти белсә ни әйтер? — дип уйлаган үзе. — Әллә яңадан аны Гайрәтләр йортына кертеп куяргамы икән? — Аннары: — Юк, миңа камчы бик кирәк шул. Мин моны яшерәм. Каен төбенә күмеп куям», — дигән фикергә килгән.

Үзе һаман үләннәр өстендә яткан камчыга карый икән. Кинәт камчы кыймылдап куйган. Янә бер кат кыймылдаган һәм кап-кара еланга әйләнгән. Шуыша башлаган. Яран, куркып, өйләренә йөгергән. Өйдә ул беркемгә дә бу хакта сөйләмәгән. Ул әле күзе күргәнгә үзе дә ышанмый икән.

Икенче көнне дә Яран каенлыкка кергән. Кичә камчы яткан урынны караган. Анда инде хәзер ике елан ята икән.

Яран бу җиргә бүтән килмәгән. Ул хәтта этисенең камчысыннан да куркып йөргән.

Күп еллар узган. Яран үскән, тынычланган. Исеме дә «Чия» дип аталган, төсе дә куе кызыл чиягә охшаган атка атланып йөри башлаган. Үзенә бик матур күп чуклы камчы да үргән.

Ә беркөнне этисенә каенлыкта күптән булган хәлне сөйләгән. Карт этисенең бик хәтере калган. Улының күз-ләренә туп-туры караган да кырыс һәм калын тавыш белән болай дип әйткән:

— Моннан ары туры юлда бул, тугры куллы бул, улым. Күршеләреңә, дусларыңа, кешеләргә тугры бул! Кеше әйберен алма! Юкса кулыңдагы камчың гына түгел, бак-чаңдагы һәр агач еланга әверелер! — дигән.

# Канатларың булса...

Бер кечкәнә кыз кошларның канатлы булуына кызыгып яшәгән.

— Ник минем канатларым юк икән? — дигән бу кыз әнисенә.

— Кошларның канатына кызыгасыңмы? — дигән әнисе.

— Әйе, бик кызыгам, — дигән кыз.

— Канатың булса нишләр идең, балам? — дигән әнисе. — Әллә очып китәр идеңме? Мине калдырып.

— Очып китәр идем дә... Очып кайтып та җитәр идем, сине сагынып, — дигән бу кыз.

Әнисе кызын кочагына алган. Кыз да әнисен кочаклаган.

— Канатларың булса, кулларың булмас иде. Син мине болай кочаклый алмас идең, кызым, — дигән әнисе.

Кыз шунда әнисен тагын да кысыбрак кочаклаган. Моннан соң ул кошларның канатлы булуына да кызыкмаган. Аларга ул бик яратып карый, кызганып та куя икән. Үзенең бердән-бер әнисе, әнисен кочакларга ике кулы булганы өчен шатланып яши, ди.

# Ансар

— Күрсәт әле кулыңны! Хәзер үк күрсәт, дим, нәрсә алдың, ник артыңа яшерәсең?

Ансар әтисенең кырыс тавышыннан куркып калды. Йөзендәге елмаю юкка чыкты. Әтисе шаярып сөйләшми иде.

— Мин бит аны карап кына утырам. Мин аны кабызып та караганым юк, — диде Ансар.

Кулындагы шырпы кабы шап итеп идәнгә төште.

— Син әле шырпы белән уйный башладыңмы?

Әтисе Ансарның арт ягына ике тапкыр сугып алды. Ансар елады.

— И бала-бала! Син бит шырпы белән уйнарга ярамаганны беләсең... Әтиең әле сиңа ныгытып та сукмады бугай. Йә, бетте, елама! — диде әнисе. Ул Ансарның башыннан сыйпады. — Башка вакытта кулыңа шырпы аласы булма, юкса әтиең болай гына калдырмас! — Әнисенең тавышы да, кулы да йомшак иде.

— Мин бит аны карап кына утырдым. Мин бит аны кабызып та караганым юк, — диде Ансар яңадан.

— Каян алдың син аны, ник алдың?

— Болай гына. Мич алдыннан, идәннән.

— Менә бит! Кара инде! — дип сөйләнде әнисе. — Әткәсе! Әткәсе, дим! Син бит идәндә шырпы калдырган булгансың! Кабат шырпыга тимәссеңме, улым?

— Тимәм.

Шушы сөйләшүдән соң ике көн үткәч, Ансарның кулыннан яңадан шырпы алдылар. Әтисе бу юлы өч тапкыр сукты. Нык сукты. Ансар тагын елады. Ул бу юлы шырпыны яшереп куйган җирдән табып алган иде. Ник алган? Аның белән нишләргә тели ул? Моны һич белә алмадылар. Шырпы кабы да тулы иде.

«Баланы күздән ычкындырмаска кирәк әле. Нигә ул безне тыңламый? Ник һаман шырпы ала?» — дип уйлады әнисе эчтән генә. Әтисе дә шул фикердә иде. Үзе бүлмәсенә кереп язарга утырды. Ул һәр көн шулай язып утыра. Ансар, әтисе эшләгән бүлмәгә кереп, аңа комачаулап йөрми. Чөнки әнисе ул бүлмәгә кермәскә куша. Балам, әтиеңә комачаулый күрмә, ул эшләп утыра, ди. Улым, ул ишеккә кагылма, әтиеңнең уйларын бүлдерерсең, ди. Ансарның ишеккә дә кагылганы юк. Әнкәсен тыңлый ул.

«Бүгеннән соң шырпыга тимәскә кирәк», — дип уйлады Ансар.

Икенче көнне инде аның кулында шырпы күрмәделәр.

Өченче көнне әнисе эштән соңгарак калып кайтты. Әтисенең эш бүлмәсендә ут яна. «Әтиебез эшли», — дип уйлады әнисе. Әкрен генә эчке бүлмәгә үтте. Зур өстәл артында Ансар утыра. Ул шундый тыныч, дөньясын оныткан. Әнисе улының аркасына, аның мыш-мыш сулаганда кабарып һәм төшеп куйган җилкәсенә карап торды. «Бу хәтле әтисе булса да булыр икән, — диде ана эченнән генә. — Кара инде, уйга батып утыра бит. Моның шушы кечкенә башында нинди уйлар бар икән?»

Аяк очларына гына басып, улы янына килде. Тик шул минутта ул аптырап, хәтта куркып калды. Ансарның кулында тагын шырпы иде.

— Балакаем! Бу ни эшең?!

— Мин аны кабызып та карамадым, мин аны...

— Әкренрәк! — дип бүлдерде әнисе аны. — Әтиең ишетмәсен. Балам, ник син болай? Ник без әйткәнне тыңламыйсың? Ник шырпы белән уйныйсың?

— Мин уйнамыйм. Мин уйлап утырам, — диде Ансар әкрен генә. Аның бу сүзләрендә «Кичер инде, әнкәй, ачуланма инде» дигән ялвару да бар иде.

— Нәрсә уйлыйсың? — диде әнисе, бераз йомшарып һәм гаҗәпсенеп.

— Шырпы турында уйлыйм мин, әнкәй. — Ансар, ашыга-ашыга, өстәлдәге шырпыларны шырпы кабына тутырды. Инде аның кулында бер генә шырпы калды. — Менә, әнкәй, син бу шырпыны сызсаң, ут кабына. Әткәй сызса да шулай. Кем сызса да, ут кабына. Шырпы кабындагы бөтен шыр-пыдан ут кабына. Шуңа күрә мин аларны сызмыйм.

Ә бер-вакытны мин сиңа шундый шырпы бирәчәкмен, шундый шырпы! Әтигә дә бирәм мин аны, бер кап туп-тулы шыр-пы бирәм. Юк, бер генә кап түгел, күп бирәм. Аны сызып җибәрү белән, ул чәчәк була... Әйе-әйе, ут түгел, чәчәк була, кып-кызыл чәчәк... Үземә дә күп итеп шундый шырпылар ясыйм. Сызам да, чәчәк була, сызам да — чәчәк! Кешеләр гаҗәпләнеп карый. Сызам да җиргә кадап куям. Кып-кызыл чәчәк үсеп утыра...

Әнкәсе аның сүзен бүлде:

— Җүләркәем! Юк уйлар белән башыңны катырма. Әнә әткәң уйлаган да безгә бик җиткән. Икегез дә көне-төне уйлап утыра башласагыз, мин нишләрмен? Андый чәчәк ясап булмый бит ул.

— Була, була, әнкәй!

Шулчак аяк тавышы ишетелде.

— Әткәң! — диде дә әнисе тиз генә Ансар кулындагы шырпыны алды.

Бүлмәгә әтисе керде:

— Нәрсә серләшәсез?

Ансар белән әнисе елмаеп аңа карыйлар. Ансар сәер генә итеп борын тартып куйды.

# Кем яхшы?

Беркөнне әнисе белән малае Казан урамында йөрергә чыгалар. Малай әледән-әле әнисенә нидер күрсәтә. Сатып алырга кушуы икән.

— Җитте. Күргән бер әйберне сорама, — ди әнисе.

— Акчаң бар. Мин күрдем бит, — дип өтәләнә малай.

— Минем акчаны тикшереп йөрисеңме?! Андый малай миңа кирәкми!

Малай үпкәли:

— Әти миңа ни сорасам да ала, — ди.

— Алай булгач, моннан соң гел әтиең белән генә йөрерсең, — ди әнисе.

— Йөрим шул. Синең белән йөрү кызык та түгел әле.

— Булды. Минем белән телләшеп барма. Арт ягыңа берне сыптырырмын!

— Әти минем бөтен сүземне тыңлый.

— Ул минем дә бөтен сүземне тыңлый.

— Минем сүзне күбрәк тыңлый ул.

— Бәлки, минем сүзне күбрәк тыңлыйдыр?!

— Әтием синнән яхшырак.

— Мин яхшы түгел. Һәр әйберне сиңа әтиең кебек алалмыйм.

Малай әнисе артыннан тыныч кына бара. Бераздан:

— Яхшы әни алып кайтырга кушармын да әтигә... Шуннан соң аның кем сүзен күбрәк тыңлаганын белерсең! — ди.

Инде әнисе малае алдыннан тыныч кына бара. Үзе малае-ның көннән-көн әтисенә ныграк охшый баруын, хәзер инде аның әтисе шикелле шаярта да белүен уйлый. Бераздан көлә башлый, әнисенең көлүенә малае кушыла. Алар икәү бергә рәхәтләнеп көлешәләр.

Аннан соң әнисе:

— Әйдә, мондый малайга әнә тегеннән банан сатып алмый булмас инде, — ди.

# «Дөресе аның шулай!»

Әтисе кызын балалар бакчасыннан алган. Сөйләшә-сөйләшә өйләренә кайтып баралар.

— Кызым, бигрәк күп сорау бирәсең, һаман мине сөй-ләндерәсең, тәмам арыттың бит, — ди әтисе. — Менә хәзер мин сиңа сорау бирим әле. Син җавап бир. Рәхәт-ләнеп сөйлә, — ди.

— Нәрсә сөйлим? — ди кыз.

— Бүген бакчада нинди матур уеннар уйнадыгыз? Шул турыда сөйлә.

— Без бүген бакчада, кулга-кул тотышып, түгәрәк ясап, «Сәйлән-бәйлән» уйнадык.

— «Сәйлән-бәйлән» түгел, «Әйлән-бәйлән» уены ул, кызым.

— Тәрбияче апа да «Әйлән-бәйлән» дип әйтә. Дөрес әйтми. Син дә ялгыш әйтәсең.

— Менә сиңа?! Тәрбияче апаң да дөрес әйтми. Мин дә ялгыш

әйтәм... Ничек инде алай? — ди әтисе.

— Шуны да белмисез. Үзегез зурлар. Ә без — кеч-кенәләр, сәйлән кебекләр. Шуңа күрә без «Сәйлән-бәйлән» уйнадык. Дөресе аның шулай! — ди кыз.

# Чыпчыкбай

*(Әкият)*

Ю-у-ук, борын-борын заманда түгел, бу заманда, нәкъ безнең заманда яшәгән, ди, чыпчыклар төркеме. Алар арасында булган шундый бер чыпчык — зур чыпчык, әрсез чыпчык, җитез чыпчык. Бу чыпчык акча янчыгы тапкан да баеп киткән. Чөнки янчык эчендә акча бик күп булган. Ул янчыгына тагын акча җыйган, акча җыйган...

Көннәрдән бер көнне ул, янчыгын асып, базарга очкан. Базарда бер абзый фил сата икән.

— Филеңне күпмегә бирәсең, абзый? — дигән Чыпчыкбай.

— Ал, ике генә сумга бирәм, — дигән абзый.

— Бик алыр идем дә бит, минем бер генә сум акчам бар шул, — дип алдаган Чыпчыкбай.

Абзый бераз башын кашып торган да әйткән:

— Әй, ярар инде, — дигән. Филне бер сумга биргән.

— Әйдә, Чыпчыкбай! Инде филләр янына китик! — дигән бер сумлык Фил.

— Юк, юк! Син нәрсә, Фил! Чик-чирик! Хәзер без чыпчыклар янына барабыз! — дип чыркылдаган Чыпчыкбай.

Бәхәс болай беткән: Фил дә җитез булган, тешләре үткен, авызы зур булган, Чыпчыкбайны акчасы-янчыгы белән бергә капкан да йотып җибәргән.

— Килегез! Алыгыз, ал! Бер сумга Фил бирәм! — дип, абзый моны яңадан сатуга куйган.

# Якты тәрәзә каршында

— Бабай, — диде Булат, — нәрсә уйлыйсың? Миңа да әйт әле. Си-нең уйларың бигрәк матур була.

Кәрим бабай, тәрәзәдән күзен алмыйча гына, оныгына эндәште:
— Ташлытау турында уйлыйм, улым.
— Нәрсә уйлыйсың аның турында?
— Аның беркайчан да, берни дә уйламавы хакында уйлыйм.
— Ә ни өчен Ташлытау берни дә уйламый? — диде Булат.
— Таш булганга.
— Агач уйлыймы соң, бабай? Әнә безнең бакчадагы алма агачы уйлыймы?
— Уйлый.
— Безнең бакчабыз да уйлыймы?
— Уйлый, улым... Әгәр озак итеп карап торсаң, бак-чабызның да нәрсә уйлаганын белерсең.
Булат бу бакчаның ни дә булса уйлавына ышанып та җитми. Үзе ышана да кебек. Ышанырлык итеп сөйли шул аның бабасы. Ул Булатка бер агачтагы кызыл чияләрнең күктә йолдыз булырга теләүләре, күптән шул хакта уйлаулары турын-да да сөйләгән иде.
Булат бервакыт җәй көне урман буенда бабасына чәчәк күрсәтте. Зәп-зәңгәр чәчәк иде ул.
— Бабай, бу зәңгәр чәчәк нәрсә уйлый? — дип сорады Булат.
— Ул үсеп торган җиреннән кузгала алмавы өчен кайгыра. Урман буенда йөгереп, сикереп, биеп уйный алсам иде, ди. Берәрсе мине өзәргә үрелсә, урманга кереп качар идем, ди. Аннан бер дә чыкмас идем, ди зәңгәр чәчәк.
Җәй көне шулай сөйләде бабасы Булатка. Бүген ул Булат белән ни өчендер бик аз сөй-ләшә. Кичә дә аз сөй-ләште. Өченче көн дә... Нигәдер гел тәрәзәгә карый ул.
— Кар нык яуды. Тиздән җылыта башлар. Көннәр язга китәр, — дип куйды шунда Кәрим бабай. Ләкин бу яз аны җылытырмы? Ул бөтен аркасы, хәтта бармак очлары өшегәнен, күкрәк читлегендә вакыт-вакыт нидер ишелгәнен тойды.
— Аяктан ук егылмасам, әкрен генә йөри алсам бик ярый инде, — диде аннан әллә үз-үзенә, әллә Булатка.
Әле кайчан гына Кәрим бабай үзе имәннән ясаган киң чаңгыларын кия иде. Көчле иде ул. Бигрәк тә ауга киткәндә, Ташлытауның яртысына күтәрелгәч, ул үзенең нык, көчле карт булуын сизә иде. Әйтерсең җир чыннан да зур. Әйтерсең бу зур Җир шары күккә эленеп тора. Әйтерсең таза Кәрим карт хәзер Җир шарының яртысына күтәрелгән дә, астан бөтен авыл аңа гаҗәпләнеп карый...

— Бабай, — диде шунда Булат. — Мин бакчабызның нәрсә уйлаганын белмәдем.

— Белмәгәч начар шул инде, улым. Тизрәк яз килсен иде дә, беренче булып мин кардан ачылсам иде, дип уйлый безнең бакча. Тизрәк Булатка эре-эре кыярлар, кып-кызыл помидорлар бирер идем, ди.

— Елга хәзер нәрсә турында уйлый икән, бабай?

— Елга да язны көтә. Беренче булып мин боздан арчылсам иде, ди. Елга шул хакта уйлый. Елгадагы балыклар быел синең кармакка берьюлы икешәрләп, өчәрләп, унарлап кабарга уйлыйлар.

Булат көлеп куйды:

— Бабай, дим, бабай. Ә теге кырлар, ерактагы ак кырлар нәрсә уйлый?

— Алар да кешеләргә бодай үстерер идек, яз беренче булып безгә килсен иде, дип уйлыйлар. Ә яз беренче булып Ташлытауга килә. Беренче булып Ташлытау кардан арчыла.

— Ни өчен яз беренче булып Ташлытауга килә? Таш булгангамы?

— Биегрәк булганга... Ташлытау безнең бакчадан да, елгадан да, кырлардан да биегрәк. Биек бит, кара... Күрәсеңме, улым?

Кәрим бабайны шушы кышта җирләделәр. Булатның әтисе дә, әнисе дә еламады. Түзделәр. Бабайны күмешергә килгән кешеләр дә еламады. Алар да түзделәр. Булат кына түзә алмады, бик озак елады. Ул бабасын бигрәк ярата иде шул.

Әнә инде Кәрим бабай көткән яз да килә. Ташлытау беренче булып кардан ачылды. Якты тәрәзә каршындагы бакча әле кар астында. Булатка эре-эре кыярлар, кып-кызыл помидорлар бирү турында уйлый ул, бабасы шулай әйтте бит...

Көн кояшлы. Кояш нәрсә турында уйлый икән? Билгеле, Кәрим бабай моны да белгәндер.

# Балыкчы

— Әй, малай! Нәрсә авызыңны ачып утырасың? Ал тизрәк кармагыңны. Балык капкан бит!

— Юу-ук, — диде малай әкрен генә. — Хәзер каба...

Ул тагын калкавычын күзәтергә тотынды. Чыннан да, малайның

авызы ачык. Хәзер ул, су астындагы балык булып, үз кармагын үзе кабар хәлдә.

— Әй, малай, дим!

— Шаулама!

— Исемең ничек?

— Фәрит. Балыкны куркытасың бит инде! Чиртә иде... Әйтәм бит, менә инде китте. Зур балык иде.

— Зу-ур балы-ык иде-е-е! — дип үртәдем мин аны. — Юкны сөйләмә. Суыгыз зур, балыгы бәләкәй. Зур балык кармакны хәзер кабып ала ул.

— Зур балык хәйләкәр була, зур кешеләр дә шулай. Тиз алданмыйлар. Бәләкәйләр тиз алдана. Әллә шуны да белмисеңме? Үзең зур кеше... Тик бәләкәйләрне алдарга ярамый.

— Елгагызның исеме ничек?

— Мишә.

— Мишәмени? Белмисеңдер дигән идем.

— Белмәс... Мин бөтен елганың исемен беләм.

— Касады дигән елганы беләсеңме?

— Менә аны белмим икән. Кайда соң ул?

— Ул моннан ерак түгел. Самара дигән шәһәр янында. Андагы балы-ык! Андагы балы-ык! Синең төшеңә дә керәсе юк.

— Ерактыр ул. Якын булса, ул елганы мин белер идем.

Кинәт шунда бала чагымны сагынып куйдым. Бераз чынлап, бераз шаяртып, болай дим:

— Касадыга якын гына бер авылда тудым мин үзем. Йолдыз дигән авылда. Бик матур авыл ул, йолдыз кебек. Касады елгасы Мишәдән күпкә матуррак.

Бу сүзләр Фәриткә ошап җитмәде. Күзләрендә миңа ачулану очкыны күрдем. Малай ашыгып кармагын ала башлады:

— Безнең Мишә кебек матур елга юк та әле! — Үзе кармагындагы җимне карый, үзе миңа сорау бирә: — Зурмы соң ул Касады?

— Эш елганың зурлыгындамыни? Балыгында да матурлыгында! Шулаймы?

— Әйтәм бит, шулай инде!

— Ә безнең Касады... — дип башладым мин яңадан, — Мишәдән таррак! Үзе шундый тиз ага. Тирә-ягы тулы таллар, камышлар. Суында балык кайнап тора. Чиләк белән, кул белән тотып була. Тик балык шома бит ул, тоттым дигәндә шуып китә... Касады елгасы,

беләсең килсә, үзе дә балык кебек шуып ага. Таллар, камышлар арасыннан шуа... Менә шулай. Хәзер менә уйлап кара инде. Мишә матурмы? Әллә Касадымы?

— Әйтәм бит, Мишә матур! — диде Фәрит. — Аннан... Минем бит Касадыны күргәнем дә юк.

— Минем дә аны бик күптәннән күргәнем юк шул инде, энем. Күптән киттем инде мин аннан.

— Алайса, анда балык беткәндер инде хәзер.

— Шундый күп балык бетәмени инде?!

— Бетә, диләр шул...

Фәрит җайлап кына кармагын болгап алды.

— Ярый, энем. Сау бул!

— Әйтәм бит, балыкны куркытасың. Сау бул, абый!

# ЭЧТӘЛЕК

## Шигырьләр

Бүген миңа ни булган? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Курчакларым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Минем урын . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Галстуклы кәҗә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Укый белә эти дә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Энем бар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Хәтерлә әле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Җиде чебеш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Кая киткән? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Тамчы тотам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Кызык рәсем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Кемдер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Ак куян . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Әбиләргә барганда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Син, мин һәм карга . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Үскәнемне күрмиләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Сандугач турында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Җил исте дә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Ачып куйдым капкасын . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Күренеп тора . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Колак сәгате . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Песи күзе турында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Яу, яу! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Күк-күү! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Күбәләк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Нишләр, әй, бу оя... . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Кунак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Өч үрдәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Кыен хәл . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Хаталы шигырь *(Мәсьәлә)* . . . . . . . . . . . . . . . .
Иң зур кеше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Авылга яңгыр килә . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Дусларың гына булсын! . . . . . . . . . . . . . . . . .
Ә сәгать келт-келт итә . . . . . . . . . . . . . . . .

Тояклар җирне кага . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Дусларым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Хәй күршесе Хөсәен . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Крокодил күрдек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Кыюлык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Торналар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Самолёт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Кыш рәсеме . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Ничә кабат чиртте? *(Мәсьәлә)* . . . . . . . . . . . . .
Кошлар һәм ташлар . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Бездә шулай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Авызсыз багана . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Кара ат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Дөньяда бер эт бар иде . . . . . . . . . . . . . .
Ике мин . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

# Хикәяләр

Бүген төнлә күккә кара . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Тау таптым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
«Сагындыңмы, улым, авылны?» . . . . . . . . . . . . .
Чуклы камчы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Канатларың булса... . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Ансар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Кем яхшы? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
«Дөресе аның шулай!» . . . . . . . . . . . . . . .
Чыпчыкбай *(Әкият)*. . . . . . . . . . . . . . . . . .
Якты тәрәзә каршында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Балыкчы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Литературно-художественное издание

Для детей дошкольного и школьного возраста

**Мингалим** Рустам
(**Минлегалимов** Рустам Галиевич)

# Три утёнка

Казань. Татарское книжное издательство. 2012

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

Мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балалар өчен

**Мингалим** Рөстәм
(**Миңлегалимов** Рөстәм Гали улы)

# Өч үрдәк

Мөхәррире *Т. Р. Шакирова*

Бизәлеш мөхәррире *Р. Х. Хәсәншин*

Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Л. И. Матвеева*

Корректоры *Г. Г. Габдуллаҗанова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 28.11.2012. Форматы 84x108$^{1}/_{16}$.

Шартлы басма табагы 7,56. Тиражы 3 000 д. Заказ

«Татарстан китап нәшрияты» ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.

Тел./факс: (843) 519-45-22.

**http://tatkniga.ru**

**e-mail: info@tatkniga.ru**

**Безнең китапларны түбәндәге адреслар буенча сатып алырга мөмкин:**

Казан, Декабристлар урамы, 2.

Татарстан китап нәшриятының маркетинг бүлеге. Тел.: (843) 519-45-35.

Казан, Бауман урамы, 29/11.

Татарстан китап нәшриятының фирма кибете. Тел.: (843) 292-03-18.

«Татмедиа» ААЖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.

420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.